Республика Татарстан

Совет Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы Советы

РЕШЕНИЕ КАРАР

Менделеевск ш.

19.06.2026 ел № 48

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районында
вазифага билгеләнгәндә үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм
мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында,
шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ
булмаган балаларының керемнәре,
мөлкәте һәм мөлкәти характердагы
йөкләмәләре турында белешмәләр
бирергә тиеш булган гражданнар, муниципаль
хезмәткәрләрнең муниципаль хезмәт
вазыйфалары исемлеген раслау хакында

Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Кодексының 6 статьясына, «Коррупциягә каршы көрәш турында " 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның ук 8, 8.1 статьяларына таянып, шулай Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы җирле үзидарә органнарының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелгән эшчәнлеген оптимальләштерү максатларында, Менделеевск муниципаль районы Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында вазифага билгеләнгәндә үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә тиеш булган гражданнар, муниципаль хезмәткәрләрнең муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеген әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Совет рәисе Р.Р. Искәндәров

Татарстан Республикасы Менделеевск
муниципаль районы Советының 2026
елның 19 июнендәге 48 нче номерлы
карарына 1 кушымта

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында вазифага билгеләнгәндә үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә тиеш булган граждannar, муниципаль хезмәткәрләрнең муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеге

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында вазыйфаларның югары, әйдәүче һәм өлкән төркеменә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфалары.